ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БҮЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел № 7

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче Яңа Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 24 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Яңа Бүләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 октябрендәге 43/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче Яңа Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 24 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленә 12.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче Яңа Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Яңа Бүләк авылында янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү колонкасы һәм янгын сүндерү җиңсәсе сатып алу)»;

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Яңа Бүләк авылында су челтәрен алыштыру)».

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 24 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылында гражданнар җыены карарына:
«-беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Яңа Бүләк авылында янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү колонкасы һәм янгын сүндерү җиңсәсе сатып алу)»;

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Яңа Бүләк авылында су челтәрен алыштыру)».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Яңа Бүләк авыл җирлеге, Яңа Бүләк авылы, Г.Тукай ур., 38 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С.Сагетдинов